| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ТИМЯШЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТИМӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.10.2020 ел Тимәш ав. № 2

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлегенең Тимәш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районының Тимәш авылы җирлеге Тимәш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2020 елның 13 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта үткәрергә дип билгеләргә.

2. Лениногорск муниципаль районының Тимәш авылы җирлеге Тимәш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2020 елның 13 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта үткәрергә дип билгеләргә.

3. Лениногорск муниципаль районының Тимәш авылы җирлеге Тимәш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2020 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта үткәрергә дип билгеләргә.

4. Лениногорск муниципаль районының Тимәш авылы җирлеге Тимәш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын 2020 елның 13 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта үткәрергә дип билгеләргә.

5. Лениногорск муниципаль районы Тимәш авыл җирлеге Тимәш авылында халык җыенын үткәрү өчен яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүлү тәртибен билгеләргә.

6. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Тимәш авыл җирлеге Тимәш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Ялгыз пенсионерлардан тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 200 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?:

- авыл җирлеге чикләрендә юлларны карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

Әлеге карарны Тимәш авылы, Утыз Имәни урамы, 71А йорт – җирле үзидарә бинасы, Киров урамы, 2 нче йорт – авыл мәдәният йорты бинасы, нефтьүткәргечләр урамы, 20 нче йорт – Ромашкино РНУ утырышлар залы, Киров урамы, 1А нче йорт – «Карлыгач» балалар бакчасы бинасы, Лесная урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Тимәш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.М.Сираев